| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.05.2021 ел Баулы шәһәре №64

Татарстан Республикасы Баулы
муниципаль районында ирекleләр
хәрәкәтен үстерүнең муниципаль
ресурс үзәген төзү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 27 декабрендәге 2950-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә ирекleләр хәрәкәтен (волонтерлыкны) үстерү концепциясе нигезендә, Баулы муниципаль районы территориясендә ирекleләр хәрәкәтен активлаштыру һәм үстерү максатларында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Яшьләр дөньясы» күппрофильле яшьләр үзәге муниципаль бюджет учреждениесе базасында ирекleләр хәрәкәтен үстерүнең муниципаль ресурс үзәген (алга таба - муниципаль Ресурс үзәген) төзергә.

2. Муниципаль ресурс үзәге турында кушымтада бирелгән Нигезләмәне расларга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасары И.И. Хөснуллинага йөкләргә.

Җитәкче И.И. Гөзәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 17 маендагы
64 номерлы карары белән расланган

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында ирекләләр хәрәкәтен үстерүнең муниципаль Ресурс үзәге турында
НИГЕЗЛӘМӘ

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында ирекләләр хәрәкәтен үстерүнең муниципаль Ресурс үзәге (алга таба - муниципаль Ресурс үзәге) эшчәнлегенең оештыру-эчтәлекле нигезен билгели һәм регламентлаштыра.

1.2. Үз эшчәнлегендә муниципаль Ресурс үзәге Россия Федерациясе Конституциясе, «Хәйрия эшчәнлеге һәм ирекләлек (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы федераль законга, 1996 елның 12 гыйнварындагы «Коммерциячел булмаган оешмалар турында» 7нче номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 29 декабрендәге 2403-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган 2025 елга кадәрге чорда Россия Федерациясе дәүләт яшьләр сәясәте нигезләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 27 декабрендәге 2950-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә ирекләлек (волонтерлык) үсеше концепциясенә, «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, дәүләт буйсынуындагы учреждениеләрнең ирекләләр (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ирекләләр (волонтерлык) оешмалары белән үзара эшчәнлек тәртибен раслау турында» 2019 елның 16 апрелендәге ПУ-223 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указына, әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Муниципаль Ресурс үзәгенең үз символикасы һәм атрибутикасы булырга мөмкин.

2. Муниципаль Ресурс үзәге эшчәнлегенең максатлары һәм бурычлары

2.1. Муниципаль Ресурс үзәгенең төп максатлары һәм бурычлары түбәндәгеләр:

- ирекләләр эшчәнлегенең нәтиҗәле системасын булдыру юлы белән муниципаль районның социаль-икътисадый үсеше дәрәҗәсен һәм халыкның тормыш сыйфатын күтәрү;

- ирекләләр булган гражданнар инициативаларын һәм проектларын системалы үстерү һәм аларга ярдәм итү;

- гражданнар җәмгыяте, ирекләләр оешмаларының һәм ирекләләрнең, муниципаль башкарма хакимият органнары көчләрен берләштерү (консолидацияләү);

- ирекләрне һәм ирекләр оешмаларын җәлеп итү һәм аларга ярдәм итү;

- ирекләрнең корпоратив мәдәниятен формалаштыру, ирекләр булган кешеләрне мотивацияләү, «гомерлек волонтерлык» алымын гамәлгә ашыру;

- ирекләр, ирекләр оешмалары, бизнес-структуралар, коммерциячел булмаган оешмалар, мәгариф оешмалары, ММЧ һәм ирекләр хезмәтеннән файдаланучылар арасында үзара хезмәттәшлекне оештыру;

- муниципаль районда волонтерлык оешмаларына һәм барлык гамәлдәге һәм потенциаль ирекләргә һәрьяклап ярдәм күрсәтүне тәэмин итү;

- ирекләр хәрәкәтенә теләктәшлек күрсәтү һәм аны үстерү белән шөгыльләнүче оешмаларга һәм физик затларга региональ һәм федераль дәрәҗәдә финанслауның төрле формаларын алу мөмкинлеген бирү;

- федераль һәм региональ проектларны һәм программаларны муниципалитетта тормышка ашыру;

- волонтерлык оешмаларын һәм программаларын мәгълүмати тәэмин итүне булдыру;

- ирекләр (волонтер) оешмалары җитәкчеләрен һәм белгечләрен укыту;

- ирекләрнең, аларның тәҗрибәләренең, проектларының һәм тәҗрибәләренең системалы исәбен алып бару;

- ирекләр (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучы гражданнарга матди булмаган ярдәм чараларын гамәлгә ашыру;

- ирекләр эшчәнлегенең үсеш дәрәҗәсенә системалы мониторинг ясау.

3. Муниципаль Ресурс үзәге эшчәнлеге юнәлешләре:

- Җиңү волонтерлыгы (истәлекле урыннарны һәм хәрбиләр каберләрен төзекләндерү; ветераннарга ярдәм һәм ветераннар оешмалары белән хезмәттәшлек итү; «Бердәм эш көннәре» форматында Бөтенроссия акцияләре уздыру; «Үлемсез полк» халык йөрешен волонтерлык белән тәэмин итү; Бөтенроссия тарихи квестларын уздыру; «Җиңү волонтерлары» иҗтимагый гражданлык-патриотик тәрбия үзәкләре эшен мәгариф оешмаларында оештыру һ.б.);

- социаль волонтерлык (халыкның якланмаган катламнарына ярдәм күрсәтү, шулай ук хайваннар турында кайгыртуга бәйле эшчәнлек);

- вакыйгалаларга бәйле ирекләлек (волонтерларны спорт, мәгариф, социаль, мәдәни характердагы вакыйгаларны оештыруга һәм уздыруга җәлеп итү);

- медицина волонтерлыгы (дәвалау-профилактика учреждениеләрендә ирекләлек, массакүләм һәм спорт чараларына медицина ярдәме күрсәтү кысаларында ярдәм күрсәтү, ирекле санитар-профилактик эш, донорлык);

- мәдәни-агарту волонтерлыгы (музейларда, китапханәләрдә, мәдәният йортларында, театрларда, кинотеатрларда, мәдәни үзәкләрдә, паркларда һ.б. үткәрелә торган мәдәни юнәлештәге проектларда ирекле эшчәнлек);

- гадәттән тыш хәлләрдә волонтерлык (гадәттән тыш хәлләрне профилактикалауда һәм бетерү, халык арасында куркынычсызлыкны популярлаштыруда экстрен чаралар күрүдә ярдәм итү);

- культурно-просветительское волонтерство (добровольческая деятель-ность в проектах культурной направленности, проводимых в музеях, библи-отеках, домах культуры, театрах, кинотеатрах, культурных центрах, парках и т.д.);

- волонтерство в чрезвычайных ситуациях (содействие службам экстрен-ного реагирования в профилактике и ликвидации чрезвычайных ситуаций, популяризации культуры безопасности среди населения);

- серебряное волонтерство (добровольческая деятельность, в которую включены люди старшего возраста, занимающие активную гражданскую позицию и имеющие ценный опыт, безвозмездно участвующие в решении социальных проблем и реализующие волонтерские проекты разной направленности);

- көмеш волонтерлык (актив гражданлык позициясен биләүче һәм социаль проблемаларны хәл итүдә түләүсез катнашучы һәм төрле юнәлештәге волонтерлык проектларын гамәлгә ашыручы өлкән яшьтәге кешеләр кертелгән ирекле эшчәнлек);

- корпоративное волонтерство (добровольческая деятельность, направленная на вовлечение представителей коммерческих структур в социально-значимую деятельность на безвозмездной основе и реализацию их личностного потенциала);

- экологическое волонтерство (добровольческая деятельность в области защиты окружающей среды и решения экологических проблем, способствующая формированию экологической культуры).

- корпоратив волонтерлык (коммерция структуралары вәкилләрен социаль әһәмияткә ия эшчәнлеккә түләүсез нигездә җәлеп итүгә һәм аларның шәхси потенциалын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән ихтыярый эшчәнлек);

- экологик волонтерлык (әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик мәдәниятне формалаштыруга ярдәм итә торган экологик проблемаларны хәл итү өлкәсендә ирекле эшчәнлек).

4. Муниципаль Ресурс үзәге эше механизмы

4.1. Муниципаль Ресурс үзәге «Яшьләр дөньясы» күппрофильле яшьләр үзәге (алга таба - Яшьләр үзәге) муниципаль бюджет учреждениесе базасында үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра.

4.2. Муниципаль Ресурс үзәген Яшьләр үзәге белгече җитәкли, аның вазыйфаи бурычларына муниципаль Ресурс үзәге белән җитәкчелек керә (алга таба муниципаль Ресурс үзәге җитәкчесе).

4.3.Муниципаль Ресурс үзәге җитәкчесе Яшьләр үзәге җитәкчесенә буйсына.

Муниципаль Ресурс үзәге җитәкчесе:

- муниципаль Ресурс үзәге эшчәнлегенә гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашыра һәм үзенә йөкләнгән вазыйфаларны һәм бурычларны үтәгән өчен шәхси җавап тота;

- үзенә йөкләнгән бурычларны тиешенчә үтәү буенча муниципаль Ресурс үзәге эшен оештыра, муниципаль Ресурс үзәге эшен регламентлаучы норматив документацияне эшли һәм актуальләштерә;

- муниципаль ресурслар үзәгенең агымдагы эшчәнлеген планлаштыруны һәм оештыруны тәэмин итә;

- волонтерлар көче белән муниципаль ресурс үзәге эшчәнлеген документация белән, методик һәм мәгълүмати тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

- куелган максатларга һәм бурычларга ирешү өчен Яшьләр үзәгенең матди-техник базасын, оешманың мәгълүмат ресурсларын файдалана;

- җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән, оешмалардан, предприятиеләрдән, учреждениеләрдән муниципаль ресурслар үзәге компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча материаллар соратып ала;

- муниципаль Ресурс үзәге эше турында хисап әзерли;

- волонтерлар хәрәкәтен камилләштерү өлкәсендә билгеләнгән тәртиптә методик тәкъдимнәр әзерли һәм раслауга тәкъдим итә, муниципаль Ресурс үзәге эшчәнлеген яхшырту буенча тәкъдимнәр кертә.

---